РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
РУНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЫРЫҢГЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

26 июнь 2023 ел

№ 1-79

ТР Буа муниципаль районының Ырыңгы авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, 2013 елның 26 июнендәге 5-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль норматив актны законнарга туры китерү максатларында, Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 26 февралендәге номерлы Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлеге Советы 1-64 карары (13.02.2020 № 1-84, 20.10.2020 № 1-4, 23.11.2020 № 1-6, 23.12.2020 № 1-8, 22.06.2021 № 4-22, 15.07.2021 № 4-22, 06.02.2023 № 3-70, 07.04.2023 № 2-73 карарлары редакциясендә) белән расланган ТР Буа муниципаль районының Ырыңгы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (текст буенча алга таба–Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертегез:

1.1. 24.3 пункты.:

1 нче пунктчаны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлеге Советның «ТР Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 8 июнендәге 1-77 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Ырыңгы авыл җирлеге башлыгы

Р.И. Гордеев